**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«19» 11 2024 ел Яр Чаллы ш. № 5188

ТР Тукай муниципаль районы «Князево урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы «Князево урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы «Князево урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 12 октябрендәге 3437 номерлы карары, 2024 елның 06 февралендәге 347 карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Житәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.Р. Хәбибуллин

Муниципаль район Башкарма комитетының 2024 елның «19» 11 5188 номерлы карарына 1 кушымта

2024 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү Князево урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум). | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Мәктәпкә әзерләнү» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Мәктәп алдыннан» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районының
«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү
Князево урта гомуми белем бирү мәктәбе»
МБГББУ директоры _______________ Н.А. Мамаева

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә
хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ
җитәкчесе урынбасары _______________ Р.Р. Йосыпова

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү Князево урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Мәктәпкә әзерләнү»**- күзәтүләр үткәрү, чагыштыру, объектның күрсәтелгән һәм яңа үзлекләрен, аның мөһим һәм әһәмиятсез характеристикаларын билгеләү, үзлекнең чагыштырмалылыгын аңлау, төп нәтиҗәләр ясау күнекмәләрен үстерүгә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 50,4 кв.м., балалар саны - 12.

2. **«Мәктәп алдыннан»**- бәйләнешле сөйләм, фонетик ишетү, иҗади фикерләү, хәрәкәтләрнең координациясе һәм вак моторикасы, язучы кулның хәрәкәт аппараты мускуллары, күрү һәм хәрәкәт факторлары функцияләрен үтәүче төрле эшчәнлек төрләре аша баланың төрле яклы үсешенә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 50,4 кв.м., балалар саны - 12.

ТР Тукай муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү Князево урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ директоры _______________ Н.А. Мамаева